СОВЕТ АЛЕКСАНДРОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
АЛЕКСАНДРОВКА АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ

РЕШЕНИЕ КАРАР

« 21» сентябрь 2020 ел № 5

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Александровка авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында Советның 2017 елның 21 августындагы 60 номерлы карары белән расланган Нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

«Мәҗбүри пенсия иминияте системасында индивидуаль (шәхсиләштерелгән) исәпкә алу турында» Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 08 июнендәге 181-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Сарман муниципаль районының «Александровка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы:

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы «Александровка авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турындагы 2017 елның 21 августындагы 60 номерлы Совет карары белән расланган Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 нче кушымтаның 7 нче бүлегендәге 3 пунктның 6 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6) индивидуаль (шәхсиләштерелгән) исәпкә алу системасында теркәлүне раслаучы документ, хезмәт шартнамәсе (контракт) беренче тапкыр төзелгән очраклардан тыш;».

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Интернет челтәрендә Сарман муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Александровка авыл җирлеге
Советы Рәисе А.Р.Гафиятуллин